| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

23.03.2018 249-п

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Думской» су алу корылмасының санитар саклык зонасы проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына 2016 елның 10 ноябрендәге ТАТ БГЛ 01626 ВР лицензияне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы районнарындагы территориаль бүлегенең проектның дәүләт санитария-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында 29.05.2017 № 16.08.01.000.Т.000004.05.17 санитария-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук ПлемРепродукт ҖЧҖ тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Дымской» су алу корылмасының санитар саклык зонасы проекты нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Думской» су алу корылмасының санитар саклык зонасы проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә №122, 123 су алу скважиналарының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Думской» су алу корылмасының №122, 123 су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Думской» су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләре, су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендәге территорияләрдән хуҗалыкта файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
23.03.2018 № 249-п боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Думской» су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләре**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Думской» су алу корылмасы Спас торак пунктыннан көньяк-көнчыгыштарак 1,2 км урнашкан һәм ике: №122 (төп) һәм №123 (резерв) су алу скважиналарыннан тора.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

№122 скв.: т.к. $54^0 24'29{,}30''$, к.о. $52^0 57'00{,}30''$;

№123 скв.: т.к. $54^0 24'28{,}67''$, к.о. $52^0 57'00{,}40''$.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

Сулы горизонтның яхшы якланган булуын исәпкә алып, №122, 123 су алу скважиналарының санитар саклык зонасында беренче пояс чикләре скважиналар авызыннан 15 метрлы радиус белән билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы

Әлеге су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы икенче поясы җир асты сулары агымы буенча сузылган эллипстан гыйбарәт.

Су алу корылмасының санитар саклык зонасында икенче поясның гомуми озынлыгы $L$= 239 метр, шул исәптән җир асты сулары агымы буенча аска таба $R$ = 124 метр, җир асты сулары агымы буенча өскә таба $r$ = 115 метр.

Санитар саклык зонасында II поясның максималь киңлеге $d$ 237 метрга тигез.

Санитар саклык зонасының III поясы

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ҖЧҖ «Дымской» су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы өченче поясның гомуми озынлыгы $L$=577 метр, шул исәптән җир асты сууларыгы агымы буенча өскә таба $R$ = 385 метр, җир асты сулары агымы буенча аска таба $r$ = 192 метр.

Санитар саклык зонасында III поясның максималь киңлеге $d$ 455 метрга тигез.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
23.03.2018 №249-п боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында «ПлемРепродукт» ЖЧЖ «Думской» су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үткәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.